РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**РУКОВОДИТЕЛЬ СТАРОЗЮРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Школьная 1А село Старые Зюри , 422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
E-mail: Szur.Tul @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**
Мәктәп урамы, 1нчеА йорт, Иске Җөри авылы, 422091 тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
E-mail: Szur.Tul @tatar.ru

**КАРАР**
**№17**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
21 октябрь 2021 ел

Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 3 мартындагы 5 номерлы «Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 3 мартындагы 5 номерлы «Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында Нигезләмәгә:

1) 2 бүлектә:

А) 2.3 пунктта «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Иске Җөри авыл җирлеге бюджетыннан беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү чыгымнарын финанслау Тәртибенә:

А) 1 пунктта «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу» сүзләренә алмаштырырга;

Б) 4 пунктта «шартнамәләр төзи» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыра» сүзләренә алмаштырырга, «муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу» сүзләренә алмаштырырга.

3. Муниципаль оешмаларда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструкцияләрнең (нигезләмәләрнең) төрләренә, эчтәлегенә һәм бәян ителешенә Төп таләпләр:

1) 2 бүлектә:

А) 2.1 пунктта «Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы Кагыйдәләрендә китерелгән (ППБ 01-03) » сүзләрен «гамәлдәге янгынга каршы нормалар белән»сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Иске Җөри авыл
җирлеге башлыгы

Р.Р.Мараков